ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ҮЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

№ 4 2020 елның 2 ноябре

«Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлегенең
Иске Үзи авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Үзи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. ТР, Аксубай районы, Иске Үзи авылы, Ленин урамы, 2А йорт адресы буенча урнашкан Иске Үзи авыл мәдәният йорты бинасында 2020 елның 02 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Иске Үзи авыл җирлегенең Иске Үзи авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда үзара салым акчаларын түләүләргә Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 500 сум күләмендә акча кертүгә, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юл полотносы урнаштыру (грунт күтәрү, авыл урамнарын ком һәм вак таш белән җәю)

- вак таш сатып алу. ;

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

- җәяүлеләр кичү юлын ремонтлау (күпер), (товарлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Горький, Киров урамнарындагы сулыкларны чистарту (эшләр башкару)

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://aksubaevo.tatar.ru кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы: Н.В. Айдова